ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
25.02.2022

Иннополис шәһәре

КАРАР
№15

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98 номерлы Татарстан Республикасы Законының 15, 16 статьялары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә шәһәр территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясен төзергә, аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү комиссиясе турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш

Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү тәртибен һәм срокларын 4 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибен 5 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитетының ТКХ, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Хуззәтов

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022нче елның 25нче февраленнән 15нче номерлы Карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | |
| Белов Сергей Александрович | - җитәкче урынбасары - Иннополис шәһәре Башкарма комитетының ТКХ, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге начальнигы; |
| Комиссия рәисе урынбасары: | |
| Сагадеев Илнур Илдус улы | - Иннополис шәһәре Башкарма комитетының хокукый ярдәм бүлегенең җир мәсьәләләре буенча баш белгече; |
| Комиссия секретаре: | |
| Зөбәерова Марьяна Радиковна | - Иннополис шәһәре Башкарма комитетының ТКХ, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеген эксплуатацияләү буенча баш белгеч; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Толкушкин Геннадий Андреевич | - «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» коммерциячел булмаган автоном оешмасының төзекләндерү һәм яшелләндерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Козырицкая Анастасия Владимировна | - «Иннополис шәһәре үсеше фонды» АКО шәһәр проектлары бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әхмәтҗанов Линар Малик улы | - Иннополис шәһәре Башкарма комитетының гомуми мәсьәләләр буенча баш белгече. |

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022нче елның 25нче февраленнән 15нче номерлы Карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясе турында
Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба – Иннополис шәһәре) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару системасын эзлекле камилләштерү һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия төзелә (алга таба – Комиссия).

1.1 Комиссия Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары нигезендә төзелә.

1.2. Комиссия Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатлары Советы карарын кабул иткәнче, әлеге Нигезләмә нигезендә «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы карары кабул ителгәнче даими эшләүче һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## 2. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. Комиссия компетенциясе

Комиссия компетенциясенә керә:

3.1. Җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу системасын эзлекле камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект эшләү, шулай ук алга таба аларны гамәлгә ашыру процессын оештыру.

3.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект эшләүгә бәйле рәвештә гражданнар һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау.

3.3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гавами тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм үткәрү.

3.4. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә гавами тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирү, рекомендацияләр әзерләү һәм аларны Иннополис шәһәре Башкарма комитетына җибәрү.

## 4. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

4.1. Комиссия, кирәк булган саен, айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә җыела.

4.2. Комиссия утырышы, Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары Комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Комиссиянең һәр утырышы нәтиҗәләре Комиссия рәисе һәм аның әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырыш темасы белән бәйле материаллар теркәлә.

4.5. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре Комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны Комиссия утырышларында ике атна дәвамында карап тикшерүне тәэмин итә.

4.6. 4. 5. пунктларында күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча беркетмәдә чагыла торган карар кабул ителә.

4.7. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеген оештыруны һәм аның утырышларын үткәрүне гамәлгә ашыра. Комиссия рәисе Комиссия исеменнән җибәрелгән хатларга, бәяләмәләргә, тәкъдимнәргә, башка документларга кул куя.

4.8. Комиссия рәисе аның әгъзаларына Комиссия функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле йөкләмәләр бирергә хокуклы.

4.9. Комиссия секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

- Комиссия каравына кергән мөрәҗәгатьләрне, тәкъдимнәрне һәм гаризаларны кабул итү һәм теркәү;
- комиссия әгъзаларына чираттагы утырышның датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында мәгълүмат бирү;
- Комиссия утырышлары беркетмәсеннән кызыксынган затларга өземтәләр әзерләү һәм бирү;
- Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләр.

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022нче елның 25нче февраленнән 15нче номерлы Карарына
3нче кушымта

Шәһәр төзелешен зоналаштыру ЭТАПЛАРЫ

1. Торак зоналары.
2. Иҗтимагый-эшлекле зоналар.
3. Җитештерү һәм коммуналь зоналары.
4. Авыл хуҗалыгы файдалануы зоналары.
5. Рекреацион билгеләнештәге зоналар.
6. Махсус билгеләнештәге зоналар.
7. Инженерлык-транспорт инфраструктурасы зонасы.

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022нче елның 25нче февраленнән 15нче номерлы Карарына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе һәм сроклары

| № п/п | Эшләрнең атамасы | Вакыты |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында Карар кабул итү турында хәбәрләрне (җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү турында Карар кабул ителгәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча) халыкка җиткерү | Карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә |
| 2 | Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү | Карар кабул ителгәннән соң 30 көн эчендә |
| 3 | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы, техник регламентларның таләпләренә туры килү-килмәүгә комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын тикшерү | Проект алганнан соң 20 көн эчендә |
| 4 | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына туры килмәү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең техник регламентлар таләпләренә, генераль планына үзгәрешләр кертү хакында бәяләмә әзерләү | Проектны тикшергәннән соң 10 көн эчендә |
| 5 | Иннополис шәһәре Мэры тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында карар кабул итү | Проект буенча бәяләмә алганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча |
| 6 | Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү, иҗтимагый фикер алышулар беркетмәләрен әзерләү, иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләре турында йомгаклар ясау | 30 көннән дә артык түгел |
| 7 | Иҗтимагый фикер алышулар беркетмәләре, иҗтимагый | Иҗтимагый фикер |

| | | |
|---|---|---|
| | фикер алышулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәләр белән иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын Иннополис шәһәре Мэрына тәкъдим итү | алышулар уздырганнан соң 10 көн эчендә |
| 8 | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге советына үзгәрешләр кертү турында Иннополис шәһәре Мэры тарафыннан карар кабул итү | Проектны тәкъдим иткәннән соң 10 көн эчендә |

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022нче елның 25нче февраленнән 15нче номерлы Карарына
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе

1. «Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары басылып чыккан вакыттан (алга таба - Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты) Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен үткәрү срогы дәвамында, кызыксынган затлар Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясенә (алга таба - Комиссия) Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы.

2. Тәкъдимнәр җибәрелергә мөмкин :

- почта аша яисә тәкъдимнәрне турыдан-туры Комиссиягә тапшыру өчен башка ысуллар белән («Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясенә» тамгасы белән) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты, 420500, Россия, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Иннополис шәһәре, Спорт урамы, 114 йорт, пом. 1076 адресы буенча;

- электрон почта аша: city@innopolis.ru

Контакт телефоны 8 (843) 212-27-24

3. Тәкъдимнәр, аны бәян иткән затның тулы фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, теркәлү урынын һәм тәкъдимнәр әзерләү датасын күрсәтеп, язма рәвештә (бастырып чыгарылган яки җентекле язу белән) язылган булырга тиеш. Төгәл язылмаган, имзаланмаган тәкъдимнәр, шулай ук Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә катнашы булмаган тәкъдимнәр Комиссия тарафыннан каралмый.

4. Тәкъдимнәр үз эченә теләсә нинди материалларны ала (кәгазьдә дә, магнит йөртүчеләрдә дә). Җибәрелгән материаллар кире кайтарылырга тиеш түгел.

5. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләре тәмамланганнан соң Комиссиягә кергән тәкъдимнәр каралмый.

6. Комиссия кергән тәкъдимнәргә җавап бирми.